УДК 821.512.145-95

***Д.М. Абдуллина***

# СУФИЯН ПОВАРИСОВНЫҢ ИҖАТ ХӘЗИНӘСЕ ҺӘМ Г. ИБРАҺИМОВ МИРАСЫН ӨЙРӘНҮДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

В статье рассматривается научное и художественное творчество знаменитого ученого, педагога, именитого писателя Суфияна Поварисова. Особое внимание уделяется его историко-биографической трилогии «Заря пророка», посвященной жизни и многогранной деятельности Галимджана Ибрагимова.

**Ключевые слова:** Суфиян Поварисов, Галимджан Ибрагимов, историко-биографическая трилогия «Заря пророка».

«Бәхет…» Күренекле галим, мәртәбәле педагог, танылган язучы Шәмсетдин улы Суфиян ага Поварисов 1953 елда язган тәүге шигырен әнә шулай атый. Очраклылыкмы бу, язмыш юравымы, «бәхет – хезмәттә» дип раслаган әлеге юллар аны иҗат бакчасыннан бәхеткә илтүче сукмак башы була. Сабыр гына, хезмәтеннән ямь табып, бәхетен тоеп яшәгән бу олы затны бәхет һәм хезмәт бөтен гомере буена ике иңендәге ике фәрештәдәй озатып бара.

Татар, рус, башкорт телләрендә басылган 50 дән артык исемдәге китап, 200 дән артык фәнни хезмәтләрнең авторы, 300 ләп диплом хезмәтенә һәм дистәгә якын кандидатлык диссертациясенә җитәкчелек иткән, сугышта күрсәткән батырлыклары өчен 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, ике дистәгә якын медаль һәм бик күп рәхмәт хатлары, Башкортстан һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Башкортстанның халык язучысы дәрәҗәләренә ия булган Суфиян аганы фәрештәләре саклаган, бәхет һәм хезмәт юлдаш иткән дими, ни дисең.

Дөрес, бу беренче карашка гына шулай гади бәхет эше кебек күренә. Әлеге уңышларга ирешү, халык ышанычын һәм хөрмәтен яулау өчен утлар-сулар кичәргә, тормышның ачысын-төчесен күп татырга, хезмәтнең ачы тирен шактый йотарга туры килә әле аңа.

Суфиян ага Поварисов 1924 елның 29 августында Башкортстанның Илеш районы Тыпый авылында дөньяга килә. Аның әтисе 1925 елда үз куллары белән булдырган ике катлы йортын, шаулап торган җимеш бакчасын, сөекле тормыш иптәшен һәм алты баласын ятим итеп, якты дөнья белән бәхилләшә. Тәүге адымнарын атлаганда ата кулына тотыну мөмкинлеге булмаган Суфиянга һәр нәрсәне үз тырышлыгы белән яуларга туры килә. Дүртенче сыйныфны тәмамлауга укуын ташлый, «мең төрле кылыч киртәләр үтеп, 1939 елда җиденчене тәмамладым», дип яза ул соңрак бу хакта. Мәктәптә укыган елларында төннәрен, туганнары белән

ярыша-ярыша, өч калыпка салып чабаталар үрә. Җиденче сыйныфны тәмамлауга колхозда эшли, паспорт алуга Свердловск, Салехард тирәләрендә кырыгар градус салкында шпаллар сала, 18 яше тулуга Бөек Ватан сугышына алына. Курск дугасыннан Дрезден шәһәренә чаклы сузылган яуда Украина, Польша, Венгрия, Чехословакия, Германия җирләрен фашизм коллыгыннан азат итүдә катнаша. 1947 елда гына солдат хезмәтен тәмамлап кайта ул. Ут эченннән исән чыгарга, ач үлемне әйләнеп узарга әтисенең изге рухы, әнисенең бәхет, гомер сорап ялварган догалары ярдәм итә күрәсең.

Армиядән соң Үзбәкстанның Нәманган өлкәсендә мәктәптә хәрби хезмәт өйрәтә, үзе дә «бик яхшы» билгеләренә генә кичке мәктәпне тәмамлый. Аннары 1951–1955 елларда Казан педагогия институтының тарих-филология факультетында укып, дәрәҗәле диплом иясе була.

Белгечлек буенча хезмәт юлын ул Татарстан автономияле республикасы Актаныш районының Бурсык мәктәбендә директор буларак башлый, ике елдан Башкортстанга кайтып, «Кызыл таң» газетасына хәбәрче булып урнаша. 1960 елдан Башкорт дәүләт университетының филология факультетында эшли башлый. Фән дөньясына ул шулай килеп керә. 1966 елда кандидатлык, 1990 елда докторлык диссертацияләре яклый, 1993 елдан профессор, БДУның кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау советы әгъзасы булып тора.

Башкорт, татар язучыларының тел-стиль үзенчәлекләре буенча яңадан-яңа фәнни хезмәтләр язу, студентлар һәм яшьләрнең фәнни һәм иҗади эшләренә юнәлеш бирү, җитәкчелек итү, мәгариф өлкәсенә кагылышлы педагогика, тәрбия, мәдәният мәсьәләләрен колачлап язылган мәкаләләр һәм ярдәмлекләр, үзенең эшен дәвам итәрлек 50 гә якын шәкерт тәрбияләү – боларның һәммәсен ул җаваплылык тоеп, яратып башкара. Шуңа күрә нәтиҗәсе дә күңел канәгатьлеге кичерерлек, аның укучылары югары, махсус һәм урта белем бирүче уку йортларында остазларының эшен лаеклы дәвам итәләр.

Суфиян ага галимлекне халыкка хезмәт итү, ил алдындагы бурычын түләү буларак кабул итә, әмма рухи ашкынудан җанын ярып чыккан әдәби иҗатка омтылу аны гомере буе ташламый. «Язу эшенә мин бик соң керештем. 1953 елда, ягъни 29 яшемдә, “Кызыл таң”да “Бәхет” дигән беренче шигырем басылды. Тукай 27 яшендә зур шагыйрь булган. Шигырь бөртекләп җыйган алтын белән бер. “Алтмыш яшемдә дә мин Тукай булмам” дип курыктым. Икенчедән, тормыш шулкадәр күп күрсәтте, алар һич тә шигырь кысаларына гына сыймый. Эпик киңлекне чагылдыра торган башка жанрлар кирәк», – дип ярым җитди һәм ярым шаяру белән аңлата ул үзенең иҗат эшенә алдан ук зур максатлар куеп, киң масштабта алынуын. Әйе, күп кенә шигырьләр, поэмалар, хикәяләр, повестьлар,

драма һәм комедияләр, романнар һәм халкыбызның бөек улы Галимҗан Ибраһимовның тәүге сулышыннан алып, гомеренең ахыргы минутларына кадәр гәүдәләндергән тарихи-биографик трилогия – «Пәйгамбәр таңы» («Пәйгамбәр таңы», 2004; «Күкнең җиденче каты», «Оҗмахка бер адым», 2006) – болар барысы да аның әдәбиятыбыз мирасын баетуга керткән өлеше. Суфиян ага Поварисов күләмле соңгы әсәре кысаларында гади яшәеш агымына кайнар лава ташкынылай бәреп кергән инкыйлаб дулкыннары, аның белән килгән афәтләр һәм, гомумән, тарихның һич тә артка әйләнмәс тәгәрмәче астында калып изелгән кешелек кануннары, идеаллар, өметләр турында да сөйли. Трилогиянең үзәгендә илебездәге адәм язмышына бик тә аяусыз елларга килеп үрелгән бәхет һәм борчулар, уңыш-уңышсызлыклар, шатлык һәм үкенечләр белән тулы булган Г. Ибраһимовның гомер юлы.

Иң элек, кечкенә Галимҗан, авыруы аркасында, үз вакытында алдынгылардан саналган «Хөсәения» мәдрәсәсенә кабул ителми кала, дәрәҗәсе күпкә түбән булган Вәли мулла карамагында белем алырга тиеш була. Андагы тәртипләр белән килешмичә, башта Вәли мулла мәдрәсәсеннән, аннан Уфадагы «Галия» мәдрәсәсеннән куыла, Казан университетына керү теләге белән, авыру килеш Миасс шахталарында эшли, әмма «Галия»дә мөгалимлек итү шатлыгы, беренче хикәяләре, тәүге фәнни хезмәтләре басылу аңа канатлар куя. Революцион эшкә җигелеп, үз заманының даһилары дип санаган Ленин, Сталин кебек шәхесләр белән иңгә-иң торып алар фәрманына хезмәт итә. Шәхси тормышындыгы мәхәббәт фаҗигаләре, ата-ана күңеленә салган сагышларыннан кичергән күңел газаплары, империалистик сугыш, гражданнар сугышы, ачлык фаҗигасе, ил, халык язмышы кыл өстендә торганда гомум халык бәхете, милләт язмышы өчен үз-үзен аямый хезмәт итү, һәм… «халык дошманы» дигән кара тамга, фаҗигале үлем.

Әйе, автор үзенең әсәрен башкача тәмамлый алмый, тарих аны акка кара белән шулай язып куйган. Тик Суфиян Поварисов пәйгамбәрлек югарылыгына күтәргән героеның үлемен дә гади генә түгел, өмет яктылыгындагы вәхшилек чагылышы итеп бирә.

Галимҗан Ибраһимовның тормышын һәм күпкырлы иҗади эшчәнлеген, халкыбызның бөек улы, фаҗигале язмышлы шәхес икәнлеге турында язылган хезмәтләр күп. Трилогиядә дә ул халык бәхете өчен көрәшүче, милләт каһарманы, үз артыннан башкаларны ияртә алган, кәгъбәсенең дөреслегенә иманы камил булган, намуслы, сабыр, пәйгамбәрләр югарылыгындагы зат. Пәйгамбәрләр үлемсез була, аларның үлеме җисми үлем генә. Алар тырышлыгы белән кешеләр күңеленә иңдерелгән иман мәңгелек. Суфиян Поварисов «Пәйгамбәр таңы» трилогиясе белән, бәлки, шул фикерне дәлиллидер. Ничек кенә булмасын, ул тормышның реаль агымына, тарихи дөреслеккә һич хилафлык

китермичә искиткеч төгәллек, дәлилләнгән фактлар җирлегендә алып бара. Шул ук вакытта дәверләр җиле тигезләгән эзләрне дә эчке рухи тоемлавы белән тергезеп, күптән булган вакыйгаларга җан өреп, укучының йөрәгенә үткәреп тасвирлый. Укучыга гадилек һәм илаһилыкны берләштергән Галимҗан Ибраһим образын үзенчә тәкъдим итә.

Г. Ибраһимов шәхесе һәм иҗаты язучы өчен, күрәсең, төрле яклап үрнәк булып торган. Ул аның әсәрләрен кайтып-кайтып, төрле яклап өйрәнә. Шулай итеп ул әлеге олуг язучы иҗатын өйрәнүгә генә дә барлыгы 70 табаклы 58 хезмәт багышлаган. Шулар арасында «Г. Ибраһимов стиленең үзенчәлеге һәм аны мәктәптә өйрәнү» (1974), «Г. Ибраһимов прозасының теле һәм стиле» (1978) китаплары һәм язучы прозасын лексик яктан, фразеологик берәмлекләргә мөнәсәбәтле өйрәнүгә багышланган хезмәтләре аны әдәби иҗатны тирәнтен тоемлап, аңлап бәяләүче галим итеп күрсәтте. Аның һәр сүзнең мәгънә йөген, тексттагы кулланылышын һәм анда нинди вазифа башкаруын гына түгел, ә бу сүзне язганда әсәрне иҗат итүченең рухи халәтен, бөтен хис-кичерешләрен аңлап эш итүе сизелеп тора.

Г. Ибраһимов шәхесен һәм иҗатын өйрәнү һәм халыкка җиткерү өлкәсендә куйган хезмәтләрен исәпкә алып, Башкортстан Республикасы Авыргазы район хакимияте аны Г. Ибраһимов исемендәге премия белән бүләкли.

Суфиян аганың әсәрләре кибет киштәләрендә онытылган китаплар исемлеген тулыландыручылар түгел, аларның һәркайсы үз укучысын, үз тамашачысын тапкан әсәрләр. Аның геройлары төрле, әсәрләрендәге вакыйгалар да, вакыт чикләре дә киң, күләмле, ләкин аларның һәммәсен берләштереп торыучы бер үзенчәлек бар: алар халыкның йөрәгеннән чыккан, шуның өчен йөрәгенә үтеп керә. Аларда – яшәү фәлсәфәсе, тормыш яме, хезмәт тәме һәм җаннарны җылытырлык, иң каты күңелләрне эретерлек хисләр. Һәр вакыйга, һәр мизгел искиткеч матур тел белән бәян ителгән.

«Яратам мин сине, тормыш» дип атый ул үзенең язмышы белән тыгыз бәйләнешле повестьларының берсен. Чыннан да, аның әсәрләренең һәммәсенә тормышны яратып, иҗатыннан тәм табып яшәү рухы сеңгән.

Язучы буларак та ул бер кеше гомере дә җитмәслек зур хезмәт башкарган, шуның өстенә галимлек, педагоглык хезмәте. Әмма Суфиян ага турында сөйләгәндә аның кешелеклелеген, ихласлыгын, чиста күңеллелеген, башкалар күңеленә якты бер нур булып иңә алу сәләтен дә искәртмичә мөмкин түгел. Танышлыклары булганнар аны һәрвакыт яратып, матур истәлекләр аша күңелләрендә яңарталар. Актанышлыларга ул мәктәп янында зур җимеш бакчасы бүләк иткән, танго биергә өйрәткән, кайдадыр иҗат түгәрәкләре оештырган, режиссер да, артист та булган, үзе язган спектакльләрдә дә еш кына төп рольләрне уйнаган (үзешчәннәр арасында әлбәттә).

Ир-егеткә тиешленең һәммәсен үтәгән Суфиян ага: нигез корган, балалар үстергән, агач утырткан, тиешле чакта илне дошманнан саклаган, тыныч тормышта намусына тап төшерми халыкка хезмәт иткән. Шуңа күрә аны һәркайда хөрмәт итәләр, хезмәтләренә югары бәя бирәләр. Театр сәхнәләрендә әсәрләре куела, матбугатта алар турында фикер алышалар, шунысы әһәмиятле: аның иҗаты, әсәрләре белән олы галимнәр дә, шәкертләре дә, укытучылар да гади укучы да бердәй кызыксына. Ул бүген дә фән әһелләре өчен олпат галим, укучы йөрәген яулаган язучы булып халык күңелендә яши.

***Абдуллина Диләрия Марат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының татар телен һәм әдәбиятын укытуның бүгенге проблемалары бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*